# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**31 октябрь 2020 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 250 сумга киметеп, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Тырыш бистәсенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (вак таш түшәмәле юллар төзү, вак ташны сатып алу һәм/яки ташу, төяү, җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Тырыш торак пунктында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (Тырыш бистәсендә «Сабантуй» үткәрү өчен бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрүгә килешү буенча хезмәтләр күрсәтү);
- Тырыш бистәсендәге юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү)».

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Тырыш бистәсе, Октябрьнең 70 еллыгы урамы, 1 йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендынларында урнаштырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Әсәдуллина